КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 10 ноябрь г.Казань № 1005

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулда «12 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында, $13^1$ статьясындагы $3^1$ һәм $3^2$ өлешләрендә» сүзләрен «$13^1$ статьясындагы 2 өлешендә» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

2 нче пунктта «12 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында, 131 статьясындагы $3^1$ һәм $3^2$ өлешләрендә» сүзләрен «$13^1$ статьясындагы 2 өлешендә» сүзләренә алыштырырга;

4 нче пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фонд тарафыннан субсидия күчерү датасына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясе тарафыннан «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча

гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» Федераль законның $13^1$ статьясындагы 2 өлеше белән каралган чараларны финанслау турында яки чараларны финанслау максатка туры килмәү турында карар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2019 елның 12 сентябрендәге 1192 номерлы карары белән расланган Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясе тарафыннан «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым актлары үз көчен югалткан дип тану хакында» Федераль законның $13^1$ статьясындагы 2 өлеше белән каралган чараларны финанслау турында яки чараларны финанслау максатка туры килмәү турында карар кабул итү кагыйдәләре (алга таба – Карар кабул итү кагыйдәләре) нигезендә чараларны финанслау турында карар кабул итү;»;

алтынчы абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Министрлык» сүзенә алыштырырга;

10 нчы пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фонд тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 5 нче пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Фондның Килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1енә бу Тәртипнең 4 нче пунктындагы дүртенче – алтынчы абзацларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.»;

12 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Министрлык» сүзенә алыштырырга;

13 нче пунктның икенче абзацында «өлешле төзелештә катнашучылар» сүзләрен «гражданнар» сүзенә алыштырырга;

15 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына» сүзләрен «Министрлык» сүзенә алыштырырга;

16 нчы пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен «Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары» сүзләренә алыштырырга;

18 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Министрлык» сүзенә алыштырырга;

19 нчы пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Министрлык» сүзенә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин